

Рузаевка шәһәрендә пауэрлифтинг буенча Мордовия Республикасынын ачык беренчелеге һәм Чемпионаты булып узды. Ике конлек ярышта Рузаевка, Саранск шәһәрләре, тобәгебезнен барлык районнарыннан, Пенза һәм Тvбән Новгород олкәләреннән 130 спортчы катнашты.

Нәтижәләр бик тә шатландырды. Мәсәлән, Торбеево районы спортчылары, 18 яшькә кадәрге яшь категориясендә тәрбияләнvчеләр арасында Алексей Мишин, 48 кг га кадәр авырлык категориясендә, 300 кг нәтижә белән жинде һәм беренче тапкыр беренче спорт разряды нормативын vтәде. Кызлар арасында 57 кг га кадәр авырлык категориясендә ике спортчы: Алина Такташова белән София Лалетина чыгыш ясады. Оч тор ярышта 275 кг нәтижә белән беренче урынны ундvрт яшьлек Алина яулады. Алина Сәид кызы беренче тапкыр КМС нормативын vтәде. Без анын тырышлыгы, осталыгы, булдыклыгы турында беләбез һәм унышларына шатланабыз. София, беренче тапкыр спорт разряды нормативын vтәп, оч тор ярышта 255 кг нәтижә белән икенче урынга чыкты.
Ярышлар нәтижәләре буенча гомумкоманда урыннары тvбәндәгечә бvленде: беренче урынны Торбеево балалар – яшvсмерләр спорт мәктәбе яулады, икенче урында – Первомайск шәһәре, оченче урында - Пенза шәһәре. Тагын бер шатлыклы вакыйга: Алинә Такташова һәм София Лалетина Мордовия жыелма командасы составына керделәр һәм 2 декабрьдә Йошкар-Ола шәһәрендә узачак ПФО турнирына әзерләнәләр.